ГЛАВА
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «17» октябреннән № 45

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2023 елның 04 августындагы 480-ФЗ номеррлы Федераль закондагы үзгәрешләр, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2020 елның 11 ноябрендәге 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Язма мөрәҗәгатькә җавап Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы, компетенцияләре нигезендә аның урынбасары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе тарафыннан, кул куела. Җавап граждан тарафыннан күрсәтелгән адреска җибәрелә.

Ике һәм аннан күбрәк зат мөрәҗәгатенә (күмәк мөрәҗәгатькә) җавап мөрәҗәгатьтә җавап алучы булып яисә мөрәҗәгатькә кул куйган гражданнар коллективы вәкиле буларак күрсәтелгән затка җибәрелә. Әгәр коллектив мөрәҗәгатьтә җавап алучы билгеләнмәгән булса, җавап яшәү урынын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр исемлегендә беренче торган гражданга җибәрелә. Коллектив мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турындагы үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (кул куелган) зат тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе аларның һәркайсына күрсәтелгән почта адреслары буенча җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ формасында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта аша яки гражданның Бердәм порталында аның шәхси кабинетының адресына (уникаль идентификаторына) һәм язмача формада Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына яисә вазыйфаи затка билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына карата тәкъдим, гариза яки шикаять, шул исәптән суд карарына шикаять бирү турындагы мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәп урнаштырылырга мөмкин.

Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, ул аларның

компетенциясе нигезендә башка органга яисә вазыйфаи затка карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.».

1.2. - 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль органга яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә йә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресын (уникаль идентификатор), аны кулланган очракта, файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов